Шомарбаш  авыл җирлеге Советы Балык Бистәсе муниципаль районы Татарстан Республикасы

**КАРАР № 5**

Шомарбаш  авылы 27 апрель 2018 ел

Татарстан Республикасы Балык
 Бистәсе муниципаль районының
"Шомарбаш  авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм
 өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Шомарбаш  авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының " Шомарбаш  авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 86,87,88 Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Шомарбаш  авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Советының 16.04.2015 елның 10 номерлы карары (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш  авыл җирлеге Советының 01.12.2016 ел, № 21 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр) белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы « Шомарбаш  авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына 25.07.2017 № 7), кушымта буенча үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе  муниципаль районы Шомарбаш авылы, Совет урамы, 47 йорт; Таулар авылы, Ленин урамы, 50А йорт; Алан-Полян авылы, Я.Емельянов урамы, 6 йорт; Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авылы, Парк урамы, 10 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында  һәм Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында  һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының « Шомарбаш Шомарбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 88 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып үз көченә керә, әлеге карарның 5 пункты нигезендә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш алар үз көчендә.

5. 1 пунктның «б» пунктчасының беренче һәм икенче абзацлары, кушымтаның 9 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм өченче абзацлары 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомырбаш авыл җирлеге Башлыгы И.Н.Сафин